СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

*Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru*

**Утар Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 26 » апрель 2019 ел** **№ 90**

**Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла торган чыгымнарны юнәлдерү турында**

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында һәм «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетына җирлектәге чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Арча район Советының 2019 елның 18 апрелендәге 247 нче номерлы карары нигезендә Утар Аты авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертларны «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы ТР Законының 15 маддәсе белән каралган Утар Аты авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.

2. Әлеге Карарны Интернет телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастыру юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Утар Аты авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Р.Г.Абдуллин